**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ**

# К А Р А Р

20.11.2017 № 84

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә 2017 елның 19 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

“2018 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 380 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 190 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге:

- вак таш сатып алу, юл-урам челтәрендә вак таш -ком катнашмасыннан нигез һәм юл катламын ясау буенча хезмәтләр күрсәтү: Апаз авылы (Тукай урамы, 3 нче йорттан 14 нче йортка кадәр (Совет урамы, 49 нчы йорт (370 м) (вак таш), Базар урамы (21 нче йорттан 45 нче йортка кадәр (вак таш), Гагарин урамы, (32 дән 46 нчы йортка кадәр) янәшәдәге юл белән Совет ур., 18а (балалар бакчасы) (420 м) (вак таш); Каратай авылы (Каратай авылына керү юлы) (вак таш); Пөшәңгәр авылы (Әһлуллин урамы, 1 нче йорттан 7 нче йортка кадәр (120 м) (вак таш); нигез салу : Нагорный урамы (1нче йорттан 35нче йортка кадәр (чуерташ); Миржәм авылы (Н.Сафин урамы(12 нче йорттан 23 нче йортка кадәр); Кзыл-Игенче авылы, Дальняя урамы (5нче йорттан 6 нчы йортка кадәр) (вак таш);

2. Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

- торак пунктларда зиратларны карап тоту өчен инструментлар (бензинлы пычкы, чапкыч) сатып алу (Апаз авылы, Каратай авылы, Пөшәңгәр авылы, Миржәм авылы, Хәсәншәех авылы);

- Хәсәншәех авылында җирләү өчен кирәк-яраклар сатып алу.

- Хәсәншәех авылы зираты территориясендә агачларны санитар кисү;

3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-Апаз, Хәсәншәех, Миржәм авыллары торак пунктларында аншлаглар ясау һәм урнаштыру;

- Хәсәншәех авылында урамнарны яктыртуны карап тоту һәм ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга".

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1444 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-1418, бу 98,20% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 1380 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 97,32% тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 38 кеше тавыш бирде, бу 2,68% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. "2018 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 380 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 190 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге:

- вак таш сатып алу, юл-урам челтәрендә вак таш -ком катнашмасыннан нигез һәм юл катламын ясау буенча хезмәтләр күрсәтү: Апаз авылы (Тукай урамы, 3 нче йорттан 14 нче йортка кадәр (Совет урамы, 49 нчы йорт (370 м) (вак таш), Базар урамы (21 нче йорттан 45 нче йортка кадәр (вак таш), Гагарин урамы, (32 дән 46 нчы йортка кадәр) янәшәдәге юл белән Совет ур., 18а (балалар бакчасы) (420 м) (вак таш); Каратай авылы (Каратай авылына керү юлы) (вак таш); Пөшәңгәр авылы (Әһлуллин урамы, 1 нче йорттан 7 нче йортка кадәр (120 м) (вак таш); нигез салу : Нагорный урамы (1нче йорттан 35нче йортка кадәр (чуерташ); Миржәм авылы (Н.Сафин урамы(12 нче йорттан 23 нче йортка кадәр); Кзыл-Игенче авылы, Дальняя урамы (5нче йорттан 6 нчы йортка кадәр) (вак таш);

2. Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

- торак пунктларда зиратларны карап тоту өчен инструментлар (бензинлы пычкы, чапкыч) сатып алу (Апаз авылы, Каратай авылы, Пөшәңгәр авылы, Миржәм авылы, Хәсәншәех авылы);

- Хәсәншәех авылында җирләү өчен кирәк-яраклар сатып алу.

- Хәсәншәех авылы зиратлары территориясендә агачларны санитар кисү;

3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-Апаз, Хәсәншәех, Мирҗәм авыллары торак пунктларында аншлаглар ясау һәм урнаштыру;

- Хәсәншәех авылында урамнарны яктыртуны карап тоту һәм ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга”.

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева